# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ТЕЛӘЧЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ СОВЕТЫ

**(III нче чакырылыш)**

егерме тугызынчы утырыш

**КАРАРЫ**

21 август 2019 ел **№ 185** Теләче авылы

2014 нче елның 4 нчеапрелендә кабул ителгән «Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районында муниципаль хезмәт турында кайбер норматив-хокукый актларга үзгәрешләр кертү турында»гы 199 нчы номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында"

«Муниципаль вазыйфаларны, контракт буенча җирле администрация башлыгы вазыйфасын биләүне дәгъвалаучы гражданнар һәм муниципаль вазыйфаларны, контракт буенча җирле администрация башлыгы вазыйфасын биләүче затлар тарафыннан тапшырылган белешмәләрнең дөреслеген һәм тулылыгын тикшерү турында» Татарстан Республикасы Законының 7 һәм 10 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» 2019 елның 17 июлендәге 60-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә Теләче муниципаль районы Советы **карар кылды**:

1. «Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районында муниципаль хезмәт турында кайбер норматив-хокукый актларга үзгәрешләр кертү хакында» 2014 елның 04 апрелендәге 199 номерлы Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Советы карарына (2016 елның 15 декабрендәге 67 номерлы, 2017 елның 20 апрелендәге 84 номерлы, 2017 елның 19 июлендәге 90, 12.04.2018 елның 24 августындагы 141 номерлы, 2018 елның 13 декабрендәге 160 номерлы карар редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) күрсәтелгән карар белән расланган Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районында муниципаль хезмәт турында Нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

а) 2 Бүлектә:

– 10 статьяның 14 пунктында «Аерым категориядәге затларга Россия Федерациясе территориясеннән читтә урнашкан чит ил банкларында счетлар (кертемнәр) ачуны һәм счетлары (кертемнәре) булуны, акчалар һәм кыйммәтле әйберләр саклауны, чит ил финанс инструментларына ия булуны һәм (яисә) алардан файдалануны тыю турында» 2013 елның 7 маендагы 79-ФЗ номерлы Федераль закон» сүзләрен «Аерым категориядәге затларга Россия Федерациясе территориясеннән читтә урнашкан чит ил банкларында счетлар (кертемнәр) ачуны һәм булдыруны, акчалар һәм кыйммәтле әйберләр саклауны, чит ил финанс инструментларына ия булуны һәм (яисә) алардан файдалануны тыю турында» сүзләренә алмаштырырга.

2.Әлеге карар гамәлдәге законнар нигезендә үз көченә керә.

Теләче муниципаль
районы башлыгы И.Ф. Зарипов